## ***Белдерү.***

Гаиләбелән тыгыз элемтәде эшләү.

Балалар туган телнеӊ тәмен, аныӊ гүзәллеген, моныӊ тоеп үссеннәр, туган телен бар телләрдән дә өстен куеп яратсыннар өчен нишләргә кирәк соӊ? Иӊ утемле чараларныӊ берсе –гаилә белән тыгыз элемтәдә эшләү. Әти – әниләрнеӊ телгә мөнәсәбәте балаларда күзге кебек чагылыш таба. Әти – әнисе туган телдә камил сөйләшкән бала да тел үзенчәлекләрен җиӊел үзләштерә, шигырьләрне шома сөйли, мәкаль – әйтемнәрне аӊлап куллана, әкиятләрнеӊ тәрбияви әһәмиятен дөрес кабул итә.

Баланыӊ теле ачылганчы, аныӊ өчын җыр – көйләрне, такмак – такмазаларны әти – әниләр, әби – бабайлар иҗат итә, шулар, аркылы ата – аналарныӊ балага карашлары, өмет – теләкләре юралган була.

Мәктәпкәчә яшьтәге баланыӊ күп вакыты, тормышы, нигездә, гаиләдә һәм балалар бакчасында уза. Аныӊ өйдә әти – әнисеннән, әби – бабасыннан алган беренче тәэсирләрен, дөньяны танып белүен бакчада тәрбиячеләр, педагоглар дәвам иттерә.

Милли бәйрәмнәр – халыкны берләштерә торган чараларныӊ берсе. Бакчабызда бу бәйрәмнәр гаилә белән бакча арысында тыгыз элемтәләр урнаштыра, ә әзерлек вакытында бәйрәмнәрнеӊ тарихы, милли мәдәниятебез үрнәкләре тирәнтен өйрәнелә.

Без  әти – әниләр беләнбергәлеп музейларга экскурсияләр, ә кул эшләреннән, рәсем – иллюстрацияләрдән күргәзмәләр оештырабыз, борынгы көнкүреш җиһазларыбелән бакчабызның минимузей почмагын баетабыз, әби – бабаларыбыз тудырган матурлык серләренә төшенәбез, төрле шөгыльләрдә бай тәҗрибә туплыйбыз. Балаларыбыз милли бәйрәмнәр белән дә танышалар, әти – әниләр өчен бу темалар “Татарча өйрәнәбез” дигән стендларда чагылыш таба.

Безнең әби – бабайларыбыз тәрбия чаралары турында махсус китаплар да укымаган, ә халык педагогикасы ярдәмендә нинди уңышларга ирешкән, үз үрнәкләрендә балаларында бик күп матур сыйфатлар тәрбияләгән. Аларның акыллы киңәшләрен, зирәк кисәтүләрен, үгет – нәсихәтләрен үтәп, әти – әниләр белән бергәләп, кечкенәдән үк нәниләребез күңеленә тәрбия орлыкларын салсак, туган телебезгә, җиребезгә мәхәббәт тәрбияләсәк, туган телебез хәзинәләренә ныклы сукмак салыныр иде.